КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 17 май г.Казань № 337

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Рус теле һәм әдәбияты өлкәсендә югары һәм урта һөнәри белем бирү программалары буенча фәнни-педагогик эшчәнлекне гамәлгә ашыручы галимнәргә һәм укытучыларга ярдәм күрсәтү буенча грантлар бирү турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2016 ел, 20 сентябрь, 661 нче карары белән расланган Рус теле һәм әдәбияты өлкәсендә югары һәм урта һөнәри белем бирү программалары буенча фәнни-педагогик эшчәнлекне гамәлгә ашыручы галимнәргә һәм укытучыларга ярдәм күрсәтү буенча грантлар бирү турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Рус теле һәм әдәбияты өлкәсендә югары һәм урта һөнәри белем бирү программалары буенча фәнни-педагогик эшчәнлекне гамәлгә ашыручы галимнәргә һәм укытучыларга ярдәм күрсәтү буенча грантлар бирү турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2016 ел, 20 сентябрь, 661 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 12 февраль, 78 нче; 2020 ел, 30 гыйнвар, 49 нчы; 2020 ел, 19 май, 408 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Рус теле һәм әдәбияты өлкәсендә югары һәм урта һөнәри белем бирү программалары буенча фәнни-педагогик эшчәнлекне гамәлгә ашыручы галимнәргә һәм укытучыларга ярдәм күрсәтү буенча грантлар бирү турындагы нигезләмәгә, аны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итеп, үзгәреш кертергә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин